## Кереш сүз

Һәр халыкның, милләтнең үз йөзен саклап калырга омтылуы табигый күренеш. Әлеге катлаулы чынбарлыкта ил-халыкның милли үзаңы, менталитеты, теле, әдәбияты, сәнгате зур әһәмияткә ия булып, җентекле анализ сорый. Телебез материалында бу юнәлештә җитди эш алып барыла. Соңгы берничә елда гына да илебезнең башка төбәкләрендә яшәүче аерым халыкларга, шул исәптән, татарларга гына хас булган милли-мәдәни үзенчәлекләрне чагылдырган, бу телләрнең этнокультура лексикасын өйрәнүгә багышланган уңышлы хезмәтләр дөнья күрде. Шулай да, татар милли мәдәнияте, аның этнокультурасы белән бәйле лексикасын өйрәнү эше әлегә башланып кына килә.

Татар халкының туган теле материалында чагылыш тапкан тарихын, гореф-гадәтләрен, әдәби осталыгын, дөньяны кабул итүен, менталитетын ачыклау күп хезмәт куюны сорый торган катлау эш.

Фәнни хезмәтләрдә урын алган фикерләрдән аңлашылганча, теләсә нинди этносның тулаем мәдәниятен өйрәнү өчен тормыш-чынбарлыкның бөтен юнәлешләрен дә берләштерә торган “кеше” төшенчәсен үзәккә алу мөһим. Аеруча, кешенең эчке дөньясы – хис-кичерешләре, рухи дөньясы, яшәү шартлары, тарихы белән бәйле вакыйгалар, гореф-гадәтләре, йолалары игътибарга лаек.

Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү юлында бер тәҗрибә булган әлеге сүзлектә каралган берәмлекләр төрле лексик-семантик төркемнәргә карый: дин, мифология, гореф-гадәтләр, йолалар белән бәйле төшенчәләр дә бар. Алар татар халкы формалашуның әһәмиятле иҗтимагый-тарихи берәмлекләрен тәшкил итәләр. Концептларны төрле чыганаклардан туплап анализлау халыкның көнкүреше, мәдәнияте, гореф-гадәтләре үзара тыгыз бәйләнгән булуын күрсәтә. Фразеологик әйтелмәләр, мәкаль-әйтемнәр составында кулланылу үзенчәлекләренә таянып, һәр аерым берәмлекнең татар халкы этномәдәниятендә тоткан урынын билгеләргә мөмкин. Өйрәнелә торган сүзләрнең җырларда, матур әдәбият әсәрләрендә киң кулланылышы да әлеге фикерне раслый.

Сүзлек-белешмәне төзүче һәм басмага әзерләүчеләр фикеренчә, тикшеренү материалы һәм аның нәтиҗәләре хәзерге лингвистиканың актуаль юнәлешләреннән берсе булган лингвокультурологияне тирәнтен өйрәнүгә этәрер, культурологиянең, мәдәниятара бәйләнешләрнең, когнитив лингвистиканың яңа актуаль мәсьәләләрен күтәрергә һәм хәл итәргә булышыр. Тәкъдим ителә торган тикшеренү материаллары татар һәм төрки мәдәният концептлары сүзлекләренә кертерелергә мөмкин. Тел материалын анализлауга мондый якын килү лексикография өлкәсе үсешендә бер адым булачак.